**РАСЛЫЙМ**

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары**
**Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе**

**В.Г.Шәйхразыев**

**Бөтендөнья татар конгрессы “Татарлар” газетасы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә үткәрелүче “Мин-укытучы” конкурсы**

**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

1. **Гомуми нигезләмәләр**

1.1. “Мин-укытучы” конкурсның (алга таба Конкурс) оештыручылары – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты (алга таба Конгресс), Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба Министрлык) һәм “Татарлар” газетасы (алга таба газета);
1.2. Конкурс турында Нигезләмә конгрессның рәсми сайтында (https://tatar-congress.org) “Рәсми басма” сәхифәсендә урнаштырыла.
1.3. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар һәм бүләкләр тапшырыла;
1.4. Конкурска бер генә хезмәт килсә/яисә бер хезмәт тә кермәсә, Конкурс үткәрелмәде дип таныла.

2. **Конкурсның максаты һәм бурычлары:**

2.1. Конкурсның максаты – укытучының җәмгыятьтәге ролен, дәрәҗәсен үстерү, балаларда әлеге һөнәр ияләренә хөрмәт тәрбияләү;
2.2. Балаларга укытучы һөнәренең ни дәрәҗәдә әһәмиятле, шул ук вакытта катлаулы һәм мөһим икәнлеген күрсәтү;
2.3. Укытучылар арасында үз һөнәренең фанаты булган, гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган шәхесләрне барлау, аларны халыкка таныту;
2.4. “Татарлар” газетасын популярлаштыру.

3. **Конкурсның җиңүчеләре**

3.1. Конкурс нәтиҗәләре буенча 5 җиңүче билгеләнәчәк. Оештыручылар өстәмә рәхмәт хатлары бирергә хокуклы.

4. **Конкурста катнашучылар**

4.1. Конкурста Татарстанда һәм Россия төбәкләрендә яшәүче, укытучы булып эшләүчеләр, яки эшләгәннәр катнаша ала.

4.2. Конкурста катнашучы "Конкурс номинацияләре" шартларына туры китереп, **"Мин - укытучы"** темасына язма җибәрергә тиеш. Язма белән сыйфатлы фото да җибәрү мәҗбүри.

4.3. Конкурста катнашучы әлеге Нигезләмәнең 5нче бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм күрсәтелгән шартларны, таләпләрне үтәп, язмасын **gazetavkt@mail.ru** электрон адресы буенча юлларга тиеш.

**5. Конкурсны үткәрү шартлары һәм таләпләре**

5.1. Конкурска тәкъдим ителүче язма 4 (дүрт) А4 битеннән артмаска тиеш (Times New Roman, 14 пт).

5.2. Конкурста катнашучылар «Татарлар» газетасына язылган булырга Һәм аның квитанциясенең күчермәсен **gazetavkt@mail.ru** электрон адресы буенча юлларга тиеш.

5.3. Конкурста катнашучы текстны язганчы, иң башта, үзенең исем-фамилиясен, кайсы район, авылдан булуын һәм яшен күрсәтергә тиеш. Бу таләпләр үтәлмәсә, конкурска җибәрелгән эш бәяләнми, төшеп кала.

5.4. Конкурс эшләрен кабул итү срогы тәмамланганнан соң килгән конкурс эшләре каралмый.

5.5. Конкурска старт 2024 елның 1 нче февралендә бирелә. Ул 25 нче сентябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

5.6. Конкурс җиңүчеләрен жюри сайлап ала. Җиңүчеләр исемнәре Бөтендөнья татар конгрессы сайтында 4 нче октябрьдә игълан ителәчәк. Җиңүчеләрне бүләкләү көне һәм вакыты алдан хәбәр ителә.

5.7. Конкурска җибәрелгән эшләрне оештыручылар Конгресснең сайтына куярга хокуклы. Эшләрнең лаеклыларын, фотолары белән бергә, "Татарлар" газетасында бастыру оештыручылар хокукында.